РУКОВОДИТЕЛЬ
ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО КОМИТЕТА
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
ҖИТӘКЧЕСЕ

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

Тел.: (8555) 42-50-50, факс: 42-42-67. E-mail: tuban.kama@tatar.ru, сайт: e-nizhnekamsk.ru

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

№ 1434 16 октябрь 2015 ел

## Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары вазыйфасын биләүгә конкурс турында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы» 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Түбән Кама муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәтнең вакантлы муниципаль вазыйфасын биләүгә конкурс турында Нигезләмәне раслау хакында» 2006 елның 13 октябрендәге 50 номерлы карары белән, Түбән Кама муниципаль районында муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә таянып, йөклим:

1. Муниципаль хезмәтнең вакантлы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары вазыйфасын (алга таба – вазыйфа) биләүгә конкурс үткәрергә.

Вазыйфа биләүгә конкурс үткәрү көнен 2015 елның 12 ноябренә 15:00 сәгатьтә билгеләргә. Конкурс үткәрү урыны итеп, Түбән Кама шәһәре, Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, 108 нче кабинет адресы буенча урнашкан Советлар йорты бинасын билгеләргә.

2. Расларга:

2.1. Вазыйфа биләүгә конкурс үткәрү буенча комиссия составы (1 нче кушымта).

2.2. 2 нче кушымта нигезендә вазыйфа биләүгә конкурс үткәрү шартлары.

3. Әлеге боерыкны «Нижнекамская правда» һәм «Туган як» газеталарында бастырып чыгарырга, шулай ук Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Түбән Кама муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы,
җитәкче урынбасары Р.М.Хөсәенов

Татарстан Республикасы
Түбән Кама муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесенең
2015 елның 16 октябрендәге
1434 номерлы боерыгы белән расланган
1 нче кушымта

Муниципаль хезмәтнең вакантлы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү буенча комиссия составы

| | |
|---|---|
| Камалетдинов Таһир Хатыйп улы | - комиссия рәисе, Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе; |
| Гарипов Роберт Зөфәр улы | - комиссия рәисе урынбасары, Түбән Кама муниципаль районы Советы Аппараты җитәкчесе (килешенү буенча); |
| Шамбазова Гөлгенә Камил кызы | - комиссия секретаре, Түбән Кама муниципаль районы Советының оештыру-кадрлар бүлеге җитәкчесе урынбасары (килешенү буенча). |
| Комиссия әгъзалары: | |
| Гайниева Рәхимә Хәмәт кызы | - Түбән Кама муниципаль районы Иҗтимагый советы әгъзасы; |
| Китанов Григорий Леонидович | - - Җирле ветераннар иҗтимагый оешмасы рәисе (Түбән Кама районының сугыш, хезмәт, кораллы көчләр һәм хокук саклау органнары пенсионерлары); |
| Умников Александр Витальевич | - Түбән Кама муниципаль районы Советының Хокук бүлеге җитәкчесе (килешенү буенча). |

Татарстан Республикасы
Түбән Кама муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесенең
2015 елның 16 октябрендәге
1434 номерлы боерыгы белән
расланган
2 нче кушымта

Муниципаль хезмәтнең вакантлы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү шартлары

1. Конкурсны үткәрү датасы: 2015 елның 12 ноябре.

2. Конкурс үткәрү вакыты: 15 сәгать 00 минут.

3. Конкурс үткәрү урыны: Түбән Кама шәһәре, Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, 108 нче каб., тел.42-39-03.

4. Гаризалар һәм конкурс документлары тапшыру урыны: Түбән Кама шәһәре, Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, 108 нче кабинет адресы буенча урнашкан Советлар йорты бинасы, көн саен 8 дән 17 сәгатькә кадәр (төшке аш 12 сәгатьтән 13 сәгатькә кадәр), ял көннәреннән һәм бәйрәм көннәреннән кала. Тәкъдим ителгән документларны кабул итү һәм тикшерү конкурс комиссиясе секретаре тарафыннан башкарыла.

5. Конкурста катнашу өчен гаризалар һәм конкурс документлары 2015 елның 22 октябреннән 2015 елның 11 ноябренә кадәр кабул ителә.

6. Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары вазыйфасына дәгъвачыларга квалификация таләпләре:

- эшчәнлек юнәлеше туры килә торган югары һөнәри белем булу;
- муниципаль (дәүләт) хезмәтенең әйдәп баручы яки өлкән вазыйфаларында бер елдан да ким булмаган муниципаль (дәүләт) хезмәт стажы яисә белгечлек буенча ике елдан да ким булмаган эш стажы;
- шәхси компьютерда эшли белү күнекмәләре.

7. Конкурста катнашырга теләүче затлар конкурс комиссиясенә гариза бирәләр, аңа түбәндәге документлар кушып бирелергә тиеш:

- үз кулы белән тутырылган һәм имзаланган анкета, 4 х 6 фотография, автобиография;
- паспорт яки аны алыштыручы документның ксерокопиясе;
- ИНН ксерокопиясе;
- иминият пенсия таныклыгының ксерокопиясе;
- кирәкле һөнәри белем, эш стажы һәм квалификацияне раслаучы документлар;
- һөнәри белем турында, шулай ук гражданның теләге буенча өстәмә һөнәри белем бирү турында, нотариаль яки эш (хезмәт) урыны буенча кадрлар хезмәте тарафыннан расланган гыйльми дәрәҗә, гыйльми исем бирү турында документлар күчермәләре;

- нотариаль яки эш (хезмәт) урыны буенча кадрлар хезмәте тарафыннан расланган гражданның хезмәт эшчәнлеген раслаучы хезмәт кенәгәсе һәм башка документлар күчермәләре;

- 2014 елның 1 гыйнварыннан 2014 елның 31 декабренә кадәрге чорда салым салу объекты булып торган керемнәр һәм милек хокукында үзенеке булган мөлкәт турында белешмәләр;

- муниципаль хезмәткә керүгә комачаулый торган авыру булмау турында медицина учреждениесе бәяләмәсе.

8. Гариза биргән затка, исемлекне һәм аларны алу датасын күрсәтеп, документларны кабул итү турында раслама бирелә.

9. Гражданин вакантлы вазыйфаның квалификация таләпләренә туры килмәүгә, шулай ук белән муниципаль хезмәткә керү һәм аны узу өчен муниципаль хезмәт турында законнарда билгеләнгән чикләүләргә бәйле рәвештә, конкурста катнашуга кертелми.

Вакантлы вазыйфаны биләүгә конкурста катнашудан баш тарткан очракта, граждан әлеге карарга законнарда билгеләнгән тәртиптә шикаять бирергә хокуклы.

Вакантлы вазыйфаны биләүгә конкурста катнашучы теләсә кайсы вакытта гаризасын кире алырга хокуклы.

10. Тәкъдим ителгән документларны кабул итү һәм тикшерү конкурс комиссиясе сәркатибе тарафыннан башкарыла.

11. Документларны вакытында тапшырмау, аларны тулы күләмдә тапшырмау яки рәсмиләштерү кагыйдәләрен бозып тапшыру гражданнан аларны кабул итүдән баш тарту өчен нигез булып тора.